## АНТОНИМНАРГА НИГЕЗЛӘНЕП ТӨЗЕЛГӘН ӘЙТЕЛМӘЛӘР (ГЫЙБАРӘЛӘР)

А

**Авыр** туфрагы(ң) **җиңел** булсын. (Әйтем)
**Авыр** сүземне **җиңел** үткәр. (Әйтем)

**Авыр** хәлләрне **җиңеләйтә** бераз
Күңелдәге өмет бөресе.
(С. Әхмәтҗанова)

**Авырлыкка – җиңеллек**! (Алкыш)

**Аз** да житә, **күп** тә бетә. (Әйтем)
**Аз** да түгел, **күп** тә түгел. (Әйтем)
**Аз** булса да, **күп** итеп ал. (Әйтем)
Я **айнык**, **я исерек** түгел. (Сөйләм)
Күзенә **ак-кара** күренми. (Әйтем)
**Ак-кара** дип белми. (Сөйләм)
**Акны карадан** аермый. (Әйтем)

Сине сөйдем...
"Еллар кирәк, – диден, –
Аерырга **акны карадан**..."
"Син минеке булсаң, мин – синеке:
Җил дә үтмәс, – дидем, – арадан!.."
(С. Рәхмәтулла)

Бер **алга**, ике **артка**. (Әйтем)
Ике **алга**, бер **артка**. (Әйтем)
**Алдым-бирдем** ясый. (Сөйләм)

**Алдын-артын** уйламастан, телгә килгән беренче күршенең исемен әйттем. (Г. Бәширов)

Дөнья бер **алдын**, бер **артын** күрсәтә. (Әйтем)
Бер **алдына**, биш **артына** чыга. (Сөйләм)

– **Алдыннан арты** яхшы... Йөргән җирендә дөмегеп калса, бигрәк тә яхшы, – дип уйланды.
(Г. Ибраһимов)

**Алдыңнан артың**! (Каргыш)
**Алучыга баручы**. (Әйтем)
**Алып-биреп** сөйләшә. (Сөйләм)

Синең авыл нигә **асты өскә килми**, аларга ике тиен бер акча бит.
(Ш. Камал)

**Асты** барның **өсте** бар. (Әйтем)

Шул тормышның **астын өскә** китереп
Җимерергә, тар-мар итәргә!!
Әйе,
Бу тормышны җимерер, ватар өчен
Алар килә,
Ишетәм:
Яшь көчләрнең
Аяк тавышлары ишетелә! (Һ. Такташ)

Пуп (поп) буласым жук (юк), ә корсагым **ачка тук**. (Ш. Маннур)

**Ачык** авыз, **йомык** күз. (Әйтем)
**Аязлы-болытлы** һава. (Сөйләм)

Ә

**Әвәлгесе-ахыргысы** булсын. (Әйтем)
Теге вакытларда, Хәернисаның җиләк күк чакларында әле, Шакирның, **элеге дә баягы**, һаман да шул йөгәнсез нәфеслегенә яман да саруым кайнап, йөрәгемә түзә алмыйча, бераз кабыргаларын кашып алган идем мин аның. (Р. Төхвәтуллин)

**Б**

Кирәгең юк, шигырь, туа күрмә,
**Бар** булганнан **юк** булганың артык.
(Г. Рәхим)

Исәпкә **бар,** санга **юк**. (Әйтем)

Аман кайткан кордашларын кара, –
Исәпкә **бар** да бит, санга **юк;**
Сәгать саен сирәгәя сафлар,
Кичтән исән берсе – таңга юк.
(Р. Идиятуллин)

**Барсаң кайтасы** була. (Сөйләм)
**Барып кайттым** бит. (Сөйләм)
**Барып кайтырсың** әле. (Сөйләм)
**Барыр-бармас** утыра. (Сөйләм)
**Бары-югы** беленми. (Сөйлм)
**Башланган** эш – **беткән** эш. (Әйтем)

Моның барлык сөйләгәне дин гыйльмедер,
**Баштан ахырга** кадәр ул шуны сөйләр. (Г. Утыз-Имәни)

Өйләнүең уң булсын, **башы-ахыры** шул булсын. (Әйтем)
**Баштан-аяк** карап чыга. (Сөйләм)
**Баштан-аяк** киенгән. (Сөйләм)

Мотгәрәйнең, **башы-аягы** белән чумып, бура бурап ятуын бораулаучылардан беренче булып Сапарбай күреп кайтты.
(Ш. Бикчурин)

**Башы** барның **соңы** бар. (Әйтем)
**Башыннан** алып **азагына** кадәр (тиклем, чаклы) карап чыкты.
(Сөйләм)

Фазлый сугышны **башыннан ахырына** кадәр үз җилкәсендә күтәрде, солдатка кичерергә туры килгән барлык авырлыкларны үз башыннан үткәрде. (Г. Галиев)

Журналның ("Совет әдәбияты") яңа саны килгән көн безнең өчен үзенә күрә бәйрәм була иде. Буш минутларда аны, кулдан-кулга йөртеп, **башыннан ахырынача** укып чыгасың. (А. Шамов)

Үзе **бер** карыш, сакалы **мең** карыш.
(Әйтем)

**Бүген** бар – **иртәгә** юк. (Әйтем)
**Бүген** булмаса **иртәгә**. (Әйтем)
**Бүгенге** эшне **иртәгәгә** калдырма.
(Мәкаль)
Һәр **бүгеннең иртәгәсе** бар. (Әйтем)

**В**

**Вакытлы-вакытсыз** йөри шунда.
(Сөйләм)

**Г**

**Гөнаһына** күрә **җәзасы**. (Әйтем)

**Д**

**Дошман дустан** ярала. (Мәкаль)

Әйдә **дус-дошманның** эче бер янсын, Нәҗиясен ул кемгә бирә дә, ничек итеп бирә! (Ә. Еники)

**Е**

Әйләндереп астын өскә гармунның,
Уйнап китте көйне шайтан кирегә.
Хак дигәнең әверелгәч юригә,
Инде көйлә озын көйгә син биеп
Көл елап һәм **ела,** бәндәм, син **көлеп**. (Ә. Баянов)

Син бит минем узган гомеркәем,
Ераклаша бара аралар.
**Ерагайган** саен **якыная,**
Хәтеремнән калка бит алар.
(Р. Шакирова)

**Ерак** араларны (жирне) **якын** итеп килдем. (Сөйләм)

Сагыну хисе миңа канат куйды,
**Ерак** жирне **якын** иттерде.
Мин авылыма кайттым, туган жиргә,
Күленә кайткан аккош шикелле.
(М. Кәрим)

**З**

– Хәзрәтнең дә үзен, мәсәлән, хәйлә белән мөселман театрларына илтеп, үзегез акча **жыяр** өчен, фаразан (әйтик), аның **зур башын кечкенә итеп** йөртәсез... – диде дә, күз яшьләрснә тончыгып, сүзен тәмам итә алмады. (Ф. Әмирхан)

Бүләкнең **зурысы** да, **кечесе** дә булмый. (Әйтем)

**И**

Ит **изгелек**, көт **явызлык**. (Әйтем)

Өч йөз алтмыш көн дөнья йөзе, кеше чырае күрмәстән, һич күңел ачмастан, төрмә кебек кибеттә **иртәдән** караңгы **кичкә кадәр** һәмишә (һаман) эш өстендә утырырга адәм түгел таш та чыдамас! (Ш. Мөхәммәдов)

Фәсхи белән Алтынбай, таң **иртәдән** караңгы **кичкәчә** чабып, ике тәүлектә Исәнбикәне (яланны) бетерделәр. (Г. Ибраһимов)

**Иртәдән кичкә** кадәр (чаклы) эшләделәр. (Сөйләм)

**Иртәдән кичләргә** кадәр
Янгырый хезмәт жыры. (Г. Латыйп)

Ә кояш **иртәдән кичкәчә**
Чәчәкле балкышны күзәтте...
(Х. Туфан)

**Иртә** уңмаган **кич** уңмас,
Бер уңмаса, һич уңмас. (Әйтем)

Безнең колхозга да **иртәме-соңмы** шунын берсе кайтып житә дигән **сүз** ич. (Р. Төхвәтуллин)

**Иртәнге** караңгыдан **кичке** караңгыга кадәр (чаклы) басуда эшләделәр. (Сөйләм)

**Иске** авызга **яңа** аш. (Әйтем)
**Иске** колакка **яңа** сүз. (Әйтем)
**Иске яңа** ел белән! (Котлау)

**Й**

**Йомшак** жәеп **катыга** яткыра.(**Әйтем**)

**К**

**Кайтса** кайта, **кайтмаса** юк. **(Сөйл.)**

**Кара** күздән **якты** язга атлап,
Картәтиләр килгән алмашка.
(М. Нәзиров)

Иртәгәсен аларны **караңгылы-яктылыдан** пристаньга алып **төшеп** киттеләр. (М. Әмир)

**Кәкре** атып **туры** тидерә. **(Әйтем)**

Түрәнең сөалсн (соравын) **этрафлы** (күпьяклы) аңлап бетмичә **үк** жавапка керешкән, **керделе-чыктылы** сүзләр сөйләгән.
(Г. Ибраһимов)

**Кереп-чыгып** йөри. (Сөйләм)
**Кереп чыктым** әле. (Сөйләм)
**Керер** алдыннан **чыгарыңны** уйла.
**(Мәкаль)**
**Килделе-киттеле** сөйли. (Сөйләм)

Тик ара-тирә ашыгып кына **килеп-киткәләгән** кызын юатыр **өчен** һаман аңа:
– Син, Нажия, бер дә борчылма, **бар** да жайланыр, бар да үзенең эзенә

төшәр, Алла бирсә! – дип әйтә торды. (Ә. Еники)

**Килер-килмәс** кенә калды. (Сөйләм)
**Килсә** килде, **килмәсә** юк. (Сөйләм)
**Китеп килеп** йөри. (Сөйләм)

**Китә** калсам, тагын **килермен**.
(Р. Шакирова)

Бер колактан **кереп,** икенчесеннән **чыга.** (Әйтем)
**Көн** дими, **төн** дими, килә дә җитә.
(Сөйләм)
**Көнен-төнен** белми эшли. (Сөйләм)

Бигрәк тә атаклы галимнәр, арутaлуны белмәстән, **көнне төнгә** ялгап эшләделәр. (А. Айнетдинов)

**Күпне** өмет итеп **аздан** буш (коры) калырсың. (Әйтем)

**Кыек** атып **туры тия** икән, бигрәк тә шәп. (К. Нәҗми)

М

Бер **матурга бер ямьсез.** (Әйтем)

О

**Озын** сүзнең **кыскасы,** мәрхүмә Зөләйха үтерелгән кичтә Муса әфәнде минем номерымда иде, диярсез. (З. Бигиев)

Бала чактагы дуслыклар буенча Фазыл, **олы** башын **кече итеп,** безне һаман да үз күрә, якын күрә.
(Г. Ибраһимов)

**Олы** булсаң, **кече** бул. (Әйтем)

**Олысыннан** алып **кечесенә** тиклем (чаклы, кадәр) килгәннәр. (Сөйләм)

Р

**Рәхәтеннән михнәте** күп. (Әйтем)

С

Мәхәббәткә юллар түгел такыр, –
Ничә тапкыр **сүнеп кабындым**...
Кайтмасыңны белә торып көттем,
Юлларыңа чыгып табындым.
(С. Рәхмәтулла)

Т

**Төнен дими – көнен дими,** эшли дә эшли. (Сөйләм)

**Түбән** очтан **югары** очка кадәр
Ишетелә гармун тавышы.
(Ә. Атнабаев)

Ч

**Чиле-пешле** арыш ипие. (Сөйләм)
Ярым **чынлап,** ярым **шаярып.**
(Сөйләм)

Э

**Эреле-ваклы** җиләкләрне бергә кайнаттым инде. (Сөйләм)
**Эрүле-туңлы** вакытлар да җитте.
(Сөйләм)

Мин аны күргәч, тәнем **эсселе-суыклы** булып китте. (М. Гафури)

**Эчендәге(се) тышында.** (Әйтем)

**Эчендәген** белә шешә **тышыннан** (тышыннан).
Өнәр (һөнәр) бар ирдә, бакчы, зур өнәр бар! (Дәрдмәнд)

Ю

Телләр бәйдә, куллар бәйдә, рухлар бәйдә,
Нишләргә тиеш соң мондый хәлдә бәндә?
Үзем әйтәм: җавап эзләп бусарынма (пошынма),
Бәйдә тотсаң, **юаш** эт тә **усаллана**.
(Р. Ханнанов)

**Югалтмыйча табып** булмый –
Моны яңа аңладым. (М. Нәзиров)

**Юк-бар** белән булма әле! (Сөйләм)

Шунсы гаҗәп: берәү **юкны бар** итә,
Берәү килә бөтенесе әзергә.
(Д. Гарифуллин)

"Хәсрәтләрем муеннан", – дим,
Булса да берәм-сәрәм.
**Юк** кайгымны **бар** дип сөйләп,
Күнелләрен күтәрәм. (М. Вафин)

**Юктан бар** булмаганмын бит,
Юк булырмынмы – бардан?!

...Баштан-аяк ак палата...
Яшә, "Ашыгыч ярдәм"!..
(С. Рәхмәтулла)

**Я**

Иртә **яздан** алып кара **көзгә** кадәр кырда эшләделәр. (Сөйләм)

**Якынлык ераклыкка** сәбәп. (Әйтем)

Бер **яшьлектә**, бер **картлыкта**.
(Әйтем)

**Яхшыдан яман** туган.
(Г. Ибраһимов)

## ОКСЮМОРОННАР ҺӘМ КАТАХРЕЗАЛАР

### *Оксюмороннар*

**А**

Агара, чалара әнием чәчләре...
**Агармый** тик кайгы **карасы**.
Мәйданда, мәйданда мәңгелек ут яна,
Ул – минем йөрәгем ярасы.
(Р. Вәлиев)

Суыгызны **агулы дәва** кушып куйгансыз икән. (Ф. Әмирхан)

Дүрт-биш секунд барган сүзсез, **атышсыз дуэльдә** баш миләреннән электр тогыдай әнә шулар йөгереп үтте. (М. Мәһдиев)

Чәчелеп лә ята – уйлар, җырлар,
**Ачылмаган ачыш** дөньялар...
(М. Галиев)

Сабый вактын сагынмакта һәр шагыйрь дә,
**Ачы-тәмле** хыяллардыр бу һәр шагыйрьгә. (Г. Тукай)

**Ә**

Авыр, мәшәкатьле тормышта **этиле этисезләр**, ятим балалар тагын арттыдигән сүз. ("Татарстан яшьләре" газетасы)

**Б**

Безнең ил ул – алга карап,
Артка таба йөргән ил,
Бүтән илләр белмәгәнне
Үзе генә белгән ил;
үлә-үлә яшәгән ил,
**байый-байый бөлгән** ил.
(Л. Лерон)

**Барышына килешем.** (Әйтем)

Дәртләнеп-ярсып алга ашу бу,
Ә бит мәңгегә бәхилләшү бу...
Нинди фаҗига, нинди тантана!
Ах, бар да арттa... Ах, бар да алда!
Күпме **бәхет** бу **бәхетсезлектә**,
Вакытлылыкта һәм чиксезлектә.
(Н. Измайлова)

Кичәгемнең бүгенгесе,
**Бүгенгемнең кичәгесе,**
Дөресемнең ялганыдыр,
Ялганымның чын дөресе.(Ә. Баянов)

**Г**

**Гаепсездән гаеплеләр**
килә күбрәк синең алга.
(Л. Шагыйрьҗан)

**Газаплы ләззәт**, ләззәтле газап
Җылы туфрактан гарешкә (иң югары күккә) аша.
Ходаем, берүк ярдәм ит җиргә –
Җир уҗымлаган мәлләр, ләбаса...
(Зөлфәт)

Мәхәббәткә һәйкәл булып калсын
**Газаплы** һәм **татлы гөнаһыбыз**.
(М. Әгъләмов)

Хәбирнең йөрәге әллә нинди шомлану аралаш **газаплы шатлык** белән типте. (Ш. Хөсәенов)

Әрнеттең дә ничә кабат,
Юаттың үзең азак.
**Газаптан торган шатлык** син,
Шатлыктан торган газап.
(Р. Миңнуллин)

**Д**

Мәхәббәт – **дәвасыз сырхау**.
(Әйтем)

Ул чагында аерылышып,
Ничек **дөрес ялгышканбыз**.
(М. Галиев)

**Е**

Сузылып кул житәр жирдә
Якын һәм ерак кешең,
**Ә син түз, ела елмаеп,**
Житәлсә әгәр көчең.

(Н. Әхмәдиев)

Хурлый-хурлый сокланабыз,
**елый-елый көләбез**...
Шайтан алгыры, шулай
матур яши беләбез.

(Р. Харис)

Һәм беркөнне
алсу аңкавымнан
дөньяның катысын кимерерлек
каты тешләр тәрткәч,
бәхетем эчемә сыймаганга
көлдем!
**Елый-елый көлдем** (Р. Вәлиев)

Ник дип ашыктың син шулкадәр?
Ник телэдең тилертергә
**Ерагайган саен якынаеп.**

(Р. Фәйзуллин)

Соңардым мин, хатлар язмыйм
Сиңа – **ерак якыным**. (Ф. Сафин)

Серле дөнья бул син миңа, –
Мәңге ачылмас тылсым,
Юллар читкә каерса да,
**Ерак якыным** бул син.

(Х. Мөдәрисова)

Җыр жибәрәм матур көйгә салып,
Еракгагы якын,
**Ерактагы якын** кешемә. (З. Нури)

**Җ**

Гүрстандай гамьле авылларда
Кыбырдаша **җанлы мәетләр**!

(Ш. Бабич)

Кар баскан өйләрдән **җанлы мәетләр** күтәрелеп чыгалар, юлсыз, сукмаксыз урамнар, тыкрыклар буенча, вакытсыз картаеп киткән яки шешенгән балалар... бу ризык йортына агылдылар. (Г. Ибраһимов)

Искелек үлә,
Аңарга без кабер казучылар,
Иске утлар мәңгегә сүнә,
Без –
Яңаны ягучылар!
Без –
Давыл балалары.
Без – мәңгелек.
Искелек **җанлы үлек**,
Без – мәңгелек. (Һ. Такташ)

Бар күңелләрдән җылы, **йомшак**
синең **кабрең ташы**. (Г. Тукай)

**И**

Мин Иделгә кайттым...Җиремдә дә
Сагынам таулар илен, яшермим...
Үзәннәрдә таулар җырын җырлыйм,
Мин **ирекле Кавказ әсире.**

(Р. Гатауллин)

Базар тулы коллар...
Мин дә шунда –
Шул **ирекле коллар** базарында.
Сата безне мәрхәмәтсез заман
Чит жирләрдә түгел –
Казанымда!.. (Р. Әхмәтҗанов)

Кая бармыйм – сайрый кошлар
Читлек читенә кунып;
Ирекле илемдә яшим
**Ирекле тоткын** булып.

(Р. Идиятуллин)

Кайда соң миңа тиеше
Монда бөек юлларның? –
Иртә килеп соңардым шул
**Иртә килеп соңардым.** (Зөлфәт)

Мәхәббәттән, яшьлек хисләреннән
Без **исерек идек хәмерсез.** (И. Юзиев)

Аның гомере шатлыклардан кайгы,
**Кайгылардан шатлык эзләп** үтте.
Бар төшләрен гел начарга юрап,
Өзә иде безнең үзәкне. (Р. Вәлиев)

Ява карлар, ява кайнар карлар,
Ява йөрәк ярасына.
Мәхәббәтем бүген табармын кук
**Кайнар карлар** арасыннан.
(Р. Вәлиев)

Шуннан хатын сузып яткырды
Бу котырган **камыр батырны.**
Көмеш сабына кадәр кылычны
Йөрәгенә аның батырды. (М. Җәлил)

Кузгалды **күңел** атлары:
Тизләтте, юыртты.
Биеште уйнап каршымда
**Караңгы якты.** (Р. Хисматуллин)

Шундый муллык –
Яшь сабыйлар ашка,
**Карт сабыйлар** яшькә туена.
Шундый муллык
Кайгы-шатлыкларга –
Әверелде сабан туена. (М. Әгъләмов)

**Картлык яшьлегемә** кердем...
Кирәк түгел артыгы!.. (З. Нури)

**Кичәгемнең бүгенгесе**,
Бүгенгемнең кичәгесе,
Дөресемнең ялганыдыр,
Ялганымның чын дөресе.
Мәхәббәтнең нәфрәт төсле,
Нәфрәтемнең мәхәббәттәй
күренеше –
Аның эше. (Ә. Баянов)

Пычак белән суганны
Калды инде турыйсы,
Ашка суган турыйм мин,
**Көлә-көлә елыйм** мин.
(Л. Ихсанова)

Әйләндереп астын өскә гармунның,
Уйнап китте көйне шайтан кирегә.
Хак дигәнең әверелгән юригә,
Инде көйлә озын көйгә син биеп
**Көл елап** һәм ела, бәндәм, син
көлеп. (Ә. Баянов)

Юкка чыкты бик күп теләкләргә,
Күп эшләргә булган өметләр.
Юкка яздым: "**Көлеп үләрмен!**" –
дип,
Юк, үләсе килми, егетләр!
(М. Җәлил)

**Күзле сукыр** кебек аермый да
Башладыкмы якты төсләрне? –
Ирек сөйде шагыйрь гомер бакый,
Сөймәде ул кара көчләрне.
(Р. Идиятуллин)

Ә күпме **күзле сукырлар**!
(Р. Гатауллин)

– Ә без, ди Мирвәли, муллалар артыннан **күзле сукыр** булып бара алмыйбыз инде, ди. (М. Фәйзи)

Шунда тамсын **күз яшемнең иң ачы һәм татлысы!** (Г. Тукай)

Су буенда ап-ак комлык.
Бер тавышсыз ап-ак яңгыр,
Ап-ак серләр. Ап-ак шатлык...
Җәйне сагынуыннан шулай
Мин ап-ак җәй уйлап таптым.
**Кышкы җәй**. (Р. Хисматуллин)

Тик бер кабат яз күрергә телим
Ник куркасыз **кышкы яшеннән**?
(И. Иксанова)

Л

Миңа Казан турында ишетү – **ләззәтле газап**, Сезнең Казаннан китүегезне белгәч, күңел җәрәхәтем тагын яңарды. (И. Гази)

Сагынулар мине моңлы, **ләззәтле бер сагышка** батырырлар иде.
(Ф. Әмирхан)

Газаплы ләззәт, **ләззәтле газап**
Җылы туфрактан гарешкә (иң югары күккә) аша. (Зөлфәт)

Альбина Хәлиуллинаның шигырьләрендә сөю һәм сөелү кебек төшенчәләрнең самимилеге,

моңсулыгы, шул ук вакытта **ләззәтле газаплылыгы**, иләһи бөеклеге дә чагылыш тапкан. (Л. Хәбибов)

## М

Тимер юлда рельслар да шулай
**Мәңге бергә, мәңге аерылган**.
(Ә. Атнабаев)

## Н

Дөньяда кешелек җәмгыятенең яшәвенә зур зарар сала торган кыргый көчләр бар: су басу, вулканнар ату, җир тетрәү, корылык, янгын, сугышлар. Юньсезләр кулына килеп кергән атом-төш коралы, химия... Болар күз алдындагы дошманнар. Аста күренмичә яткан дошманнар бар: алардан берсе – **надан галим**. (М. Мәһдиев)

Их, син, Сәях дустым, **нәни гигант**!
Без – ракета күк, тик бер аерма...
(Зөлфәт)

## О

Мәрьям, **олы сабыйның** баягынак караватта юашланып, буйсынып утыруыннан көлгән сыман, чын күңелдән көлеп куйды. (Н. Фәттах)

## Ө

Монда бар йолдызлар,
Ике пар күз караганга ахры,
Бик якыннар һәм бик тоныклар.
Монда юллар, сукмаклар юк.
Монда адашканнар –
**Өметсез өметлеләр**. (Р. Вәлиев)

Язның гөлләрен ал – сиңа булсын,
Синсез гөлләр миңа кирәкми.
Былбыл телләрен ал – сиңа булсын,
**Өнсез телләр** миңа кирәкми.
(Ә. Атнабаев)

Пешә-пешә туңган чагыммы ла,
**Өши-өши янган** чагыммы?
(Н. Әхмәдиев)

## П

Син дә парлы, мин дә парлы
Икебез дә **парлы ялгыз**. (Җыр)

Күңелендә исемемне
Саклыйсыңдыр, таң кызым.
Исә җилләр, кичә илләр...
Сау бул, **парлы ялгызым**!..
(Ф. Сафин)

**Парлы ялгыз**
Читләрдән караучыга без –
Туйдагы пар ат кебек!
Ә эчләрдә яра саркый
Чәерле нарат кебек... (Р. Фәйзуллин)

**Пешә-пешә туңган** чагыммы ла,
Өши-өши янган чагыммы?
(Н. Әхмәдиев)

## Р

**Рәхәт газап** бирүчем,
Сау бул, бүгенгә! (Э. Гадел)

## С

Мең савaплардан **саваплы**
Һәм изге безнең **гөнаһ**. (Л. Янсуар)

Төсләрне тараттың...
Мин сине яраттым.
Сөюем – бәхеткә илткән юл...
**Сагышлы шатлыктан** тора ул.
(Р. Вәлиев)

**Сакаллы сабый**, ник соң моны алданрак әйтмәдең?! (Ф. Хөсни)

Бу нинди **сакаллы сабый**
Шигырь китабы сайлый?
Сәерсенеп карап тордым,
Күзләрем ала алмый. (Н. Сафина)

Салкын чишмә суларын эч –
Утта янасың килсә,

Ялгыз каенны кочакла –
Парлар табасың килсә.
“Мәхәббәт тавы” бар икән
Шундый ырымы белән.
**Сакаллы сабый** шикелле
Мин дә шул тауга менәм.
(Ә. Атнабаев)

Тик **салкын җылы** бу
Әбиләр чуагы.
Язмышым соңарып,
Кызганып елмайды. (Н. Измайлова)

...Араларына чәчрәде
**салкын утлы** күз яше.
(Р. Харис)

Кайда соң, и җан кисәгем,
Миңа наз-иркәләрең.
Соңарып иртәләдем шул
**Соңарып иртәләдем**... (Зөлфәт)

**Т**

Болар безгә һәркайсы –
**Таныш түгел таныш.**
Үпкәләмәс көзгегә
Авызы булса чалыш. (Ш. Мөдәррис)

Кайчак: “Авыртмыйммы, – дисең миңа, –
Йөрәк каты куллар тиюдән?”
Елмаям, ә йөрәк кысыла
**Татлы авыртуны** тоюдан.
(Ә. Давыдов)

Мин болай да газапланам –
**Татлы,** әмма **авыр газап,**
Ләкин куркам яшәүләрдән
Бу газаптан булып азат. (Р. Харис)

Ни булган мескенкәйгә? Ул бит туйга әзерләнә иде. Әллә туй сәяхәтенә чыкканнармы? **Татлы газапка** түзә алмыйча шулай гармун уйнавымы? (Г. Әпсәләмов)

Үткәннәрнең **татлы газабында**
Син яндырчы мине, аһ яндыр!
(Р. Аймат)

Сине сөю **татлы газап**: юктыр чарам.
Тик нишлим соң?
Син бит минем йөрәктәге тирән ярам. (Г. Латыпова)

Арада ул **татлы газаптан,**
Бөтенләйгә, мәңге бушандыр!
(Р. Шәрипова)

Мин канун буенча язмыйм,
Мин каным белән язам,
Каныма манып язганда,
Язганым – **татлы җәза.**
(Ә. Синугыл-Куганаклы)

Мин түзәрмен, әйтмә тик авыр сүз –
Тик аерма **татлы кайгымнан.**
(Ә. Баянов)

Күзләремнең нурлы катламы
**Татлы-тозлы тамчы яшьләр** белән
Селтеләнеп кат-кат юылган.
(Р. Фәйзуллин)

Җырлау нигә: “Көзләр җиткәч. Синсез
Сарыларга гына сабыштым”.
Көзнең быел яктырагы килде,
**Татлырагы килде сагышның.**
(Р. Миңнуллин)

Туксан яшьлек ветераннар
Илдә ничәү бар икән?
Авылында Сафуан карт
**Тәүге соңгы Могикан**... (М. Галиев)

**Телле телсез** булган телемдәй,
Йөзем, телем һәм күземне ачтың,
Татар китабы, әй татар китабы!
(А. Хәлим)

Гөрли базар. Берәү генә тыныч.
Ымлый гына бара, сөйләми.
Дөньядагы **телле телсезләргә**
Тылмач була ала бу әби.
(Р. Әхмәтҗанов)

Мин сине, дүрт стена эченә бикләп,
**тере курчак** итәргә уйламыйм.
(Г.Әпсәләмов)

Бүген күпме **тере мәет**
тулган жиргә.
Тик исәннәр белән алар
никтер бергә. (Н. Сафина)

Ак сакалы буйлап яшьләр ага,
Тама жиргә, тама кулына.
**Һәйкәл ташларына сөялгән дә**
**Тере мәет** елый тын гына.
(Н. Әхмәдиев)

Кичерә күр, соңга калма.
Акла безнең гаепләрне,
Мәрхүмәттән мәхрүм калган
Үксез **тере мәетләрне**.
(Л. Шагыйрьҗан)

Һөнәре юк – **тере үлек.** (Мәкаль)

Сулышыма кояш нуры кирәк әле,
Тик бүлмәмә тулган куе караңгылык.
Шул чагымда ишегемнән якты бөркеп
Син керәсең өйгә **төнге кояш** булып.
(Г. Рәхим)

Җәйге кар ул,
Кышын яуган яңгыр,
Ир-атка соң ничек чыдырга?
**Төнлә чыккан кояш,**
Көндезге ай,
Аяз көндә яшен – хатын-кыз,
Хатын-кызны аңлыйм дия-дия,
Күпме ир-ат калган акылсыз!
(Н. Әхмәдиев)

Ачы хәсрәт – **төче кайгы.** (Әйтем)

Тарта эчәсе суларың,
Тарта сулыйсы һаваң.
Барабыз **табышлар эзләп,**
**Югалтуларга** табан. (Ф.Яруллин)

**Тынлык тавышын** бары тыңлагыз сез, ишетәсезме, –
пышылдыйлар жилдә бөреләр.
(Р. Әхмәтҗанов)

**У**

Гөлле тәмуг, **утлы оҗмах** түбәндә.
(Р. Сүлти)

**Ү**

Безнең ил ул – алга карап,
Артка таба йөргән ил,
Бүтән илләр белмәгәнне
үзе генә белгән ил;
**үлә-үлә яшәгән** ил,
байый-байый бөлгән ил.
(Л. Лерон)

Аптырыйм: юк изге эш ятканда да, торганда да...
Килер мәллә, кабергә мин сөрелгәч,
Кыямәт көнендә мин **үлеп терелгәч**... (Г. Тукай)

Оныткан инде күңелең
Биеккә үрелгәнне,
Сөйгәнең керфек какканда
Мең **үлеп терелгәнне...** (Зөлфәт)

Бер **үлеп терелгән** кеше
Яшәү кадерен белә.
Елыйсы чакта елый ул,
Көләсе чакта көлә. (Н. Сафина)

**Х**

Сине сөю олуг гөнаһ, төшенәм мин,
Тик нишлим соң?
Карашыңнан **хәмер эчми**
**Исерәм** мин. (Г. Латыйпова)

**Хурлый-хурлый сокланабыз,**
елый-елый көләбез...
Шайтан алгыры, шулай
матур яши беләбез.
(Р. Харис)

...Очрашулар (язган булса!) –
Ходай бирмеш төштә генә.
Фәкать төштә.
Төш –
**хыялланган чынлык** үзе.
(Р. Фәйзуллин)

**Ч**

...Сындырып сыный дөнья!
Дусларны **чәчеп җыям**.
(Р. Фәйзуллин)

Илдар үсте,
Яше – өч,
Аптырамый сүзгә һич.
"Инде мин еламыйм, – ди,
Бетереп еладым", – ди.
Өсте-башы гел акбур...
Җавап тапты бер тапкыр:
"Әни, **чиста пычрак** бу,
Кара түгел ич, ак бу!" (Г. Морат)

**Ш**

Бу таш йортта күпме йөрәк тибә,
Күпме **шатлык елый**, яшь көлә!
(Р. Фәйзуллин)

Газаплар өләшә **йөрәкләр**,
Бәхетле газаплар,
**Шатлыклы газаплар**,
Әрнүле газаплар. (Э. Шәрифуллина)

Әрнеттең дә ничә кабат,
Юаттың үзең азак.
Газаптан торган шатлык син,
**Шатлыктан торган газап**.
(Р. Миңнуллин)

**Э**

Дингез йоклый. Сылу кыздай
Таралып йоклый дингез...
Мин уяу; **эчми исергән**
Гашыйктан аңгы-миңге. (Л. Лерон)

**Эчмичә дә исерүләр**
Һичкемгә тимәс байлык.
Син булганга мин һәрвакыт
Ни исерек, ни айнык. (М. Вафин)

**Ю**

Бәхетем – бәхетсезлегем,
Шатлыгым – **сагышым** син.
Ай күреп, кояш алганда
**Югалткан табышым** син. (И. Ихсанова)

**Я**

**Якындагы ераклыкны**
Кичергән кемнәр генә!
Күзләрең миндә, башкаең
Бүтәннең иңнәрендә (Н. Әхмәдиев)

**Якынлашкан** саен **ерагая**,
Төшләреңдә күпме чакырма.
Мин ачмаган гаҗәп әкият калган
Мәгарәле зәңгәр Чатырда!
(М. Галиев)

Инде хәзер еллар үткәч
Аңлашылды **ялгыштык**:
Ул чагында икебез дә
**Ялгышмыйча ялгыштык**.
(Н. Сафина)

Үзенең атасы турындагы сүзләр Мостафа өстенә **ялкынлы яңгыр** булып яудылар. (Г. Ибраһимов)

Хисләрем күңел мичендә
**Ялкынсыз ялкынлана**. (Л. Лерон)

Кайберәүләр
Авыз ачмый җырлыйлар.
Икенчеләр
**Яшь чыгармый елыйлар**.
(М. Гыймаев)

**Акыллы юләр**
**Бай хәерче**
**Татлы агу**

***Әсәр исемнәре буларак кулланылган оксюмороннар***

"**Гап-гади катлаулы** сораулар"
(Р. Фәйзуллин)
"**Ерактагы якын** туганнар"
(Ә. Давыдов)
"**Камыр батыр**" (Әкият)
"**Табу** һәм **югалту** (юлда очрашулар)" (М. Юнысов)
"**Ут** һәм **су**" (Ә. Баянов)
"**Яхшылыкка – яманлык**" (Әкият)
"**Яшәү** белән **үлем** арасында"
(Н. Дәүли)

**А**

Кайберәүләр
**Авыз ачмый җырлыйлар**.
Икенчеләр
Яшь чыгармый елыйлар.
(М. Гыймаев)

Мин дә бит каен күңелле,
Яралы каеннарым –
Минем ак куанычларым,
Минем **ак кайгыларым**!
(Р. Миңнуллин)

Каеннар – **ак сагыш**, ак сагыш...
Коела, коела яшьләре...
Аклыкта – сагышлы пакь язмыш…
Сап-сары кара җир өсләре...
(Л. Сәгыйдуллина)

Сәбәбенә төшенергә
Кирәкми бөек акын:
Аксакта – аксак аяк та,
Ә миндә – **аксак акыл**.
(Р. Сөләйманов)

**Акыллы баш юләрлеге** –
Юләр башның акылы.
Йомшакны белмәгәннәр
Белә микән катыны?
(Н. Әхмәдиев)

Юктыр инде.
Ул чибәр кыз
Башка белән бәхет бүлеште,
Минсез бәхет юллавына
**Ак көнчеллек** белән көнләштем.
(Ә. Гаязов)

Безнең ил ул – **алга карап,**
**Артка таба йөгергән ил,**
Бүтән илләр белмәгәнне
үзе генә белгән ил;
үлә-үлә яшәгән ил,
байый-байый бөлгән ил.
(Л. Лерон)

Төче тиргәү, **ачы мактанышу**
**Нотыклары**, кермәгез сез төшкә.
(Ә. Баян)

**Аяз көндә яшен** суккан. (Әйтем)

**Аяз күктә утлы яшен** бул син,
Булма гына, зинһар, аҗаган.
Ялган, кысыр сөю хисләреннән
Алданып мин күптән алҗыган.
(Р. Сөләйманов)

**Б**

Хакыйкатьнең сытык чыраеннан
Өстен күрдем **баллы ялганны**.
(Н. Әхмәдиев)

Ходай мине җиргә яратканда
Кызганмаган бәхет, кайгыны,
Кайгылырым белән бәхетлемен,
**Бәхетләрем белән кайгылы**.
(Р. Сөләйманов)

Кыз борылып карауга, ул туктап калды.
Яфраклар... Кинәт шыбырдап, яфраклар давылы кузгалды.
Егет исенә килеп пышылдады:
– Дәшмә...Беләм...Ул бит инде
Күптән... Бу дөньядан киткән иде...
Нинди охшашлык!
**Бәхетле алдану**! (М. Галиев)

Нинди **бөек ялган** белән
Күзләренә нур салыйм?!
(Н. Измайлова)

Йөрәгемне **былбыл чакты** минем
Һәм өздереп елан сайрады. (Зөлфәт)

– Кемнәр җиңде, әй, сез хөкемдарлар,
**без катнашкан безсез сугышта**?
(Р. Фәйзуллин)

Г

Шатлана да газаплана,
**Газаптан рәхәт** таба;
Кичтән канатын сындыра,
Иртәнгә канатлана. (Ә. Атнабаев)

**Гөлле тәмуг**, утлы оҗмах түбәндә.
(Р. Сүлти)

Уйнале, башны әйләндер,
Тезләнгәнем юк күптән.
Оялсын тыйнак күңелем
**гөнаһлы гүзәллектән.**
(М. Галиев)

Д

**Диңгезләрне атлап чыга алсак та,**
Кемдер кичә алмый инешне.
(Р. Фәйзуллин)

Яулап алдым бөек дөньяны мин,
Тик ул **дөнья** һаман **тар калды**.
...Усал илләрне мин буйсындырдым,
Миңа буйсынмаган яр калды.
(Зөлфәт)

Е

Дөнья матур – исең китәрлек,
Ал кояшлы,
Зәңгәр чәчәкле,
Синең кебек **елак батырлар**
Безнекеннән зур киләчәкле.
(Ә. Рәшит)

Йөрәгемне былбыл чакты минем
Һәм өздереп **елан сайрады**. (Зөлфәт)

Без барда, бу дөнья
Әйләнмәс көлләргә!
Ил өчен без әзер
**Елмаеп үләргә**. (Р. Вәлиев)

Бабич – чәчкә атканчы өзелгән бөре.
Ул ике чор арасында **елмаеп сыктаган** көенчә ауды. (М. Кәрим)

Ж

**Җәйге кар** ул,
Кышын яуган яңгыр,
Ир-атка соң ничек чыдарга?
Төнлә чыккан кояш,
Көндезге ай,
Аяз көндә яшен – хатын-кыз.
Хатын-кызны аңлыйм **дия-дия**,
Күпме ир-ат калган акылсыз!
(Н. Әхмәдиев)

Бертуктаусыз уйный, шаярасың...
Шатлыгыңны кемнәр уяткан?!
Син бит башка. Син бит уйчан идең,
...Бу **җылы җил исә төньяктан**.
(Р. Вәлиев)

Еракта булса да үзе,
Канатларын җәйде көз.
Елның гаҗәп мизгеле –
Көзге җәй бу, **җәйге көз!**
(Р. Миңнуллин)

Су буеннан әнкәй кайтып килә,
Каз каурые алган кулына.
Эзләренә, **җылы карлар** булып,
Тал мамыгы ява тын гына.
(М. Галиев)

З

И **зәвыклы карак**,
Урла, зинһар, минем шигырьне.
(Зөлфәт)

И

Алдау...ләкин бу – **изге алдау**, дип,
Карасын салган, ап-агын кигән.
Яшьләрен яшереп, мәйданга килгән:
"Кояш күк балкып менсен дарга!.." дип...
Алдау...шулай да изге алдау бит...
(Х. Туфан)

Өзгәләнде былбыл, таңга кадәр
Җырларына җырны ялгады;

Берьялгызы белде моңлы былбыл
Горур кызның **изге ялганын**.
(Зөлфәт)

Татарларым, минем татарларым,
**Илдә илсез калган** татарым...
(Л. Лерон)

Кагылма каенга –
кагылма
**кадерле кайгыма.**
(Р. Гатауллин)

Мин тезләнеп сәждә кылам бүген
Мәхәббәтнең **ихлас ялганына**.
(Ф. Мөслимова)

К

Мәхәббәтне кышлар адаштырган,
Кышлар миңа бәхет китергән.
Мин мәңгегә чыга алмам инде
"Сөю" дигән **кайнар бураннан.**
(Р. Вәлиев)

Күңеле анын давыллы,
Шигыре – **кайнар җилле,**
Җырларына кызлар гашыйк –
Кем бирсен аңа илле? (Р. Вәлиев)

Ява карлар, ява **кайнар карлар,**
Ява йөрәк ярасына.
Мәхәббәтем бүген табармын күк
Кайнар карлар арасыннан.
(Р. Вәлиев)

**Кар** нинди **җылы**... (Н. Дәүли)

Язасы килми ваклык турында.
Язасы килә хаклык турында.
Язасы килә язгы энгердә
**Каралыктагы аклык** турында.
(Р. Фәйзуллин)

**Кар өстендә** казан **кайната**. (Әйтем)

Алмалары, алсу алмалары
Тупылдашып карга төшкәндә,
Ялкынынан язлар башлангандай,
**Карлар кайный, бозлар пешкәндәй**. (Р. Гарипов)

Кояш!.. Яңгыр!..
**Кояшлы яңгыр** бирдең,
Күз яшь аша
Елмайганымны күрдең. (Р. Гарипов)

**Көзге Сабантуйга** ул елны халык җыелды да соң инде!
("Казан утлары" журналы)

Алда кышлар.
Артта күпме кышлар.
Үткәнеме күбрәк, белмәссең.
**Кыш җылысын** язда сагынучылар
Ташкыннардан мине эзләсен.
(М. Вафин)

Әмма күрмим яуган карларны да,
Җитәкләшеп барган парларны да.
Син бит миңа бүген: "Сөям!" – дидең,
"**Кыш көнендә пешкән** чиям" – дидең. (Винисә Фәттахова)

**Кыш челләсе** тәрәзләргә
Сихри чәчкәләр суза.
Ә аларга, күбәләктәй,
Ак кар бөртеге куна. (Р. Гарипов)

Чәчәк төсен инде онытып барам...
Өстәлемдә җикән.
Бу карсыз кыш минем кышым булыр –
**Кара кышлар** җиткән. (Р. Вәлиев)

Син беләсең, сөйгән ярлар белән
**Кара төннәр көннән яктырак.**
(В. Фәттахов)

Кем мәйданда, чүлмәк итеп,
баш вата?

**Колмак баткан дәрьяда**
Таш калка. (Р. Фәйзуллин)

Урау юл сызган бит бөек атабыз,
**Коры чәй** дә булмас өстәлдә...
(Г. Афзал)

Көннәремә йолдыз булалмадың,
**Кояш булалмадың төнемдә**.
Син күкләрдән җиргә төштең инде,
Хыялымнан күчтең өнемә.
(Х. Мөдәрисова)

Еракта булса да үзе,
Канатларын җәйде көз.
Елның гаҗәп мизгеле –
**Көзге җәй** бу, җәйге көз!
(Р. Миңнуллин)

Аерылып китә утрау!
Шәп күренеш! Трагикомик
илаһи бер тамаша!
Офыклар – төсле музыка,
**Көлү катыш яшь аша**.
(Р. Фәйзуллин)

**Көннәремә йолдыз булалмадың**,
Кояш булалмадың төнемдә.
Син күкләрдән җиргә төштең инде,
Хыялымнан күчтең өнемә.
(Х. Мөдәрисова)

Кая гына бармыйм,
ниләр генә кылмыйм –
бимазалый мине
**күренә торган юклык**.
(М. Галиев)

Дөресен әйтим, мин "Яшьлегем чәчәк атканда", "Мәхәббәт җимешем син", "Авылымны өзелеп сөям", "Әниемне өзелеп яратам" кебек тәмле һәм төче сүзләр яза алмадым. Бу хәлне, үземчә, кимчелек түгел дип исәплим. **Кырыс наз** да (русча чыккан бер китабымның исеме дә "Суровая нежность") житкән безгә.
(Р. Фәйзуллин)

Гашыйк булдым, гашыйк булдым
Яр Чаллы сылуына.
Зәһәр **кышта уттай янам**,
Ис китми суыгына. (Р. Сөләйманов)

Җәйге кар ул,
**Кышын яуган яңгыр**,
Ир-атка соң ничек чыдарга?
Төнлә чыккан кояш,
Көндезге ай,
Аяз көндә яшен – хатын-кыз,
Хатын-кызны аңлыйм дия-дия,
Күпме ир-ат калган акылсыз!
(Н. Әхмәдиев)

**Л**

Язларны ләйсән китерә.
**Ләйсән – кояшлы яңгыр**.
(Р. Вәлиев)

**М**

Шпалларның кайгыларын эчеп,
Юл буенда сары гөл үсә.
Алга карыйм, алда **матур ялган** –
Кушылалар кебек рельслар.
(Р. Вәлиев)

Иң матур кыз! Иң сөйкемле!
Нинди **матур ялган**!
Ул ялганга рәхмәт.
Мине бәхетле итә алган.
(Р. Фәйзуллин)

Без доньядан нидер өмет итеп,
Офыкларга карап барганда,
Без генәме, нинди асыл затлар
Батып үлде **матур ялганга**.
(Ә. Рәшит)

**Машиналарга утырып,**
**Җәяү кайттым ат белән**.
(Шаян җыр)

**Машинага утырып, тәпи-тәпи кайттым**. (Сөйләм)

Фәрит хәзер минем өчен дошман урынына калса да, ул бит – **мәхәббәтле дошман**. (В. Касыймова)

**Н**

Язгы буран, **назлы буран** –
Мәхәббәт бураннары.
Мине никтер читләп үтте,
Җаныма уралмады. (Р. Вәлиев)

**Ө**

Язның гөлләрен ал – сиңа булсын,
Синсез гөлләр миңа кирәкми.
Былбыл телләрен ал – сиңа булсын,
**Өнсез телләр** миңа кирәкми.
(Ә. Атнабаев)

**П**

Һаман саф бала күңелне,
**Пакъ ялгышыңны** уйлыйм.
(Р. Гатауллин)

Син дә парлы, мин дә парлы
Икебез дә **парлы ялгыз**. (Җыр)

**Ү**

**Үкенмәслек ачы** булсан иде,
**Үкенерлек татлы**.
Син – **үкендерми торган үкенечем**.
(И. Иксанова)

**С**

Каеннар – ак сагыш, ак сагыш...
Коела, коела яшьләре...
Аклыкта – **сагышлы пакь язмыш**…
Сап-сары кара җир өсләре...
(Л. Сәгыйдуллина)

**Салкыннан җылынган** күңел,
Эсселектән туңган. (М. Әгъләмов)

Кышлар килде тагын табигатькә,
Күңелемә никтер моң тулды.
Тик гомерсез, **салкын тойгы-хиске**
Бүләк итмә миңа бу юлы.
(А. Хәлиуллина)

**Суга кереп коры чыгар**. (Әйтем)

Бара торгач, мамык кулы белән
Ул билемнән минем кочаклый.
Уйламаган идем **сукыр бәхетем**
Тулып ташар, диеп бу чаклы.
(М. Җәлил)

Шатлыкларым булса – сиңа булсын,
Кысыр шатлык миңа кирәкми,
Бәхетләрем булса – сиңа булсын,
**Сукыр бәхет** миңа кирәкми.
(Ә. Атнабаев)

**Сусыз юа**, җилсез киптерә. (Әйтем)

**Т**

Яшел ялкын... **Тавышсыз җыр**...
Шигъри наз. (М. Галиев)

Кешегә калган көн – **таң атмаган төн**. (Мәкаль)

Алтын алма – кулларымда.
Адәм улы, сиңа илтәм.
Аһ, шул **татлы гөнаһ** өчен
Меңнәр җирдә газап чиккән.
(Л. Янсуар)

Мәхәббәткә һәйкәл булып калсын
Газаплы һәм **татлы гөнаһыбыз**.
(М.Әгъләмов)

Йөрәгемнең иң нечкә бер кылы
Чынлап куйды **татлы сагыштан**.
(С. Гәрәева)

Көзге **татлы салкын**,
Әй, иркәли
Алландырып битең алмасын.
(Р. Гарипов)

Ут табарга өйрәнгәннән бирле
Кемнәр генә анда янмады?! –
Янмый икән әмма ут төртсәң дә
Сәясәтнең **татлы ялганы**. (Х. Әюп)

Синең белән минем Хыялларга
Коелса да бәсләр тамчысы,
**Татлы ялкын** кала иреннәрдә
Күңелләрдә – сагыш ачысы.
(А. Халиуллина)

...Аларның үз хәле хәл...
Безнең хакны кем каклар?
Колмак бата, **таш йөзә**!.. –
Шундый хәлләр, братлар!
(Р. Фәйзуллин)

**Тәмле нәрсә була** күбрәк **ачы-төче**.
(Г. Тукай)

Тик бәхеткә генә юллар ерак,
Тигән өлеш кенә – **тәти ялган**.
(Ә. Рәшит)

**Телеграм баганасы**
**Чәчәк атса** кайтырбыз.
(Р. Фәйзуллин)

Дуслар белән учак яктык
Тәнге елга буенда.
**Төн дә якты була** икән
Янда дуслар барында. (Р. Вәлиев)

Гыйшык – **тәтенсез ут**, **ачкычсыз йозак** ул. (Әйтем)

**Төче тиргәү**, ачы мактанышу
Нотыклары, кермәгез сез төшкә.
(Ә. Баянов)

**У**

Минем яуның дагалары, таптап,
Бүтән итте бөек Җир өстен...
Ә мәхәббәт миннән йөз чөерде...
Елат мине, **усал дөреслек**. (Зөлфәт)

Ул керсә төшләргә,
Күңелдә **ут-кырау**.
Көл итә күңелне
Җавапсыз бер сорау.
(Р. Сөләйманов)

**Утны ялкын** белән **сүндерә**.
(Әйтем)

**Х**

Балкый нур... дөнья кабер...роэя (төш) кабер... **хәсрәт матур**.
(Ш. Бабич)

**Ч**

Кайгыдан да, шатлыктан да
Кызык табып шашып көлә:
Шатланганда – **чәче көлә**,
Кайгырганда – яше көлә.
...Урамнарга шатлык чәчеп
Кызлар килә. (Р. Идиятуллин)

Мин үзем дә белми торган
Бер сәерлектә яшим.
**Чилләләрдә** кайчак **өшим**,
Кышларны ярып яшьним.
(Р. Фәйзуллин)

**Чиллә чагында катып (туңып) үлгән**. (Әйтем)

**Чыкмаган кояшка кызынган**.
(Әйтем)

Башын күрмәмешкә салып,
Иптәшләр яннан узды.
Дошманым үтеп барышлый
Ярдәмгә кулын сузды.
– Рәхмәт, – дидем. – Гомерлеккә
Иң якын дустым бул син.
Йөз ялган дустың булганчы,
Бер **чын дошманың** булсын.
(М. Вафин)

**Э**

Салкыннан җылынган күңел,
**Эсселектән туңган**. (М. Әгъләмов)

**Я**

**Ягымлы ялган** булса да
килешә хатын-кызга. (М. Галиев)

Кичер мине!
Тик
Соңарып килгән
**Якты әрнү, якты сыкраулардан**
Мәхрүм итә күрмә күңелне. (Зөлфәт)

Мине күр төшендә,
**Якты сагыш** булып жанына сарылыйм! (И. Иксанова)

Очрашканда сүзләр бетми безнең,
Аерылганда туа **якты сагыш**.
(Х. Хөснуллин)

Калыр бәхет, **якты сагыш**...
(Калмас бит кара ялган?) (Ф. Сафин)

...Аңлашылмас **якты сагыш** белән
Бу якларда үзәк өзелә... (С. Гәрәева)

Башын күрмәмешкә салып,
Иптәшләр яннан узды.
Дошманым үтеп барышлый
Ярдәмгә кулын сузды.
– Рәхмәт, – дидем. – Гомерлеккә
Иң якын дустым бул син.
Йөз **ялган дустың** булганчы,
Бер чын дошманың булсын.
(М. Вафин)

Үз Ләйләңне эзләп йөргән чакта
Кисәтсә дә чатта кызыл ут,
Кул бирәсең кайчак жиде ятка,
**Ялган матурлыкка** кызыгып...
(Р. Закиров)

Тик мең авыр жыр тумыйча,
Сүнсә бер балкыш кебек,
Кысыр болыт, **ялкынсыз ут**,
Канатсыз аккош кебек.
(Х. Мөдәрисова)

Кинәт жырны бүлеп, жир тутырып
**Янгырап, чыңлап китте буш тынлык**.

Бар дөньяны сихри моңга күмде
Бөре кебек кенә бер кошчык.
(Х. Мөдәрисова)

Кайгыдан да, шатлыктан да
Кызык табып шашып көлә:
Шатланганда – чәче көлә,
Кайгырганда – **яше көлә**.
...Урамнарга шатлык чәчеп
Кызлар килә. (Р. Идиятуллин)

**Бәхетле газап**
**Зәңгәр кара**
**Изге сугыш**
**Изге ялган**
**Кара аккош**
**Кара бәхет**
**Коры диңгез**
**Кызыл кара**
**Пычаксыз сую**
**Сүзсез аңлашу**
**Телсез кыңгырау**

***Әсәр, рубрика, мәкалә исемнәре буларак кулланылган катахрезалар***

**“Карак мулла”** (Г. Ибраһимов)
**“Үлем уены”** (Ф. Кәрим)
**“Дию мулла”** (Әкият)
**“Ялган пәйгамбәр”** (Әкият)
**“Тозлы бал”** (Ф. Садриев)
**“Кара йолдызлар”** (Г. Рәхимов)
**“Әйтелмәгән әйтер сүзләрем”**
(С. Рәхмәтулла)
**“Кар нинди жылы...”** (Н. Дәүли)
**“Һәйбәт гайбәт”** (рубрика исеме)
**“Бай Америка ачлары”** (мәкалә исеме) h.б.

## ЭНАНТИОСЕМИЯЛЕ СҮЗЛӘР

**Абау:** 1. Соклану, гаҗәпләнү хисләрен белдерә. Мәсәлән: Зөбәйдәнең сеңеле уйнап йөри, *Абау* матур! Күзем тимәсен. (Һ. Такташ)
2. Җирәнү һ.б.ш. хисләрне белдерә. Мәсәлән: – *Абау*! *Абау*! Бу асрау дигән нәрсәләрдә һич оят юк. (Г. Камал)

**Алу:** 1.Кемне дә булса эшеннән чыгару, эш урыныннан азат итү. Мәсәлән: Үткән ел халык буталышы уңае белән Карасу авылында өч мулланың указын *алганнар* иде бит. (Т. Гыйззәт)
2. Кемне дә булса эшкә, урынга кабул итү. Мәсәлән: Миңлебаев өйләнгән. Авылда тимерче булып торып кала икән! Шуның буенча дүшәмбе көн үк аның урынына кеше *алганнар*. (Г. Ибраһимов)

**Әй:** 1. Шатлану, шатлыклы гаҗәпләнү, соклану, канәгатьлек хисен, мактану төсмерен чагылдыру өчен кулланыла. Мәсәлән: Минем атым беренче урынны алды бит, *әй!* (Ә. Айдар) – Ну ут малай, *әй!* (Һ. Такташ) Катык *әй* тәмле дә булды соң! (Ә. Фәйзи)
2. Үкенү, борчылу, газаплану, кайгыру, кызгану хисләрен белдерү өчен кулланыла. Мәсәлән: *Әй* бала, бала, Себер китәрлек нинди генә гаепләрең булды соң? (Т. Гыйззәт) *Әй*, мескенкәй, нинди көннәргә төште бит. (М. Гафури) *Әй*, бәхетсез кыз, күзеңнән колак каккансың бит. (К. Тинчурин)

**Әйе:** 1. Ризалыкны белдереп, раслауны белдереп җавап биргәндә кулланыла. Мәсәлән: Зиннәт, үзенең бәхәсләшүен онытып, идәнгә караган килеш башын ия-ия: "Дөрес, дөрес... *әйе!*" – дип пышылдады. (Г. Әпсәләмов)
2. Кireләнү, каршы килү, ышанмау һ.б.ш.ларны белдерү өчен кулланыла. Мәсәлән: Ш ә й х а т т а р б а б а й. Бәрәр минут ял иттер, арыгандыр. – *Әйе*, арыган сиңа... (Г. Гобәй)

**Бәясез:** 1. Кыйммәтле, кадерле; бәя биреп кенә үлчәп бетереп булмый торган. Мәсәлән: Бөек Ватан сугышы яугирләренең батырлыклары ил алдында *бәясез*.
2. Үтә арзан, бәясе түбән. Мәсәлән:
– Күпме тора? – дип сорый Әбүзәр абзый аучыдан.
– Миллион! – ди тегесе.
Ул елларда акчаның *бәясез* чагы булса да, Әбүзәр абзый уйлый-уйлый да, кыйбатсынып, киекне алмый китә. (Г. Әпсәләмов)

**Бетерү:** 1. Билгеле бер эшне, төзелешне тәгәлләү, тәмамлау, ахырга китереп җиткерү. Мәсәлән: Быел алар яңа өй *бетерделәр*. (Сөйләмнән)
2. Юкка чыгару, юк итү; әрәм-шәрәм итү. Мәсәлән: Эчемлеккә хиреслеге аркасында бөтен йорт-җирен, бар мөлкәтен *бетерде*. (Сөйләмнән)

**Бурыч:** 1. Түләп кайтару шарты белән вакытлыча алына торган яки алынган нәрсә. Мәсәлән: Әсфәндияр байтак кына *бурычланды*. (Ш. Камал)
2. Түләп кайтару шарты белән вакытлыча бирелә торган яки бирелгән нәрсә. Мәсәлән: Ул безнең кебек ярлы шәкертләргә бирми, тик аталары бай булган ышанычлы шәкертләргә генә *бурыч* бирә. (М. Гафури)

**Буяу:** 1. Буяп, ягып матурларга тырышу. Мәсәлән: Хуҗа хатын киенгән, ясанган, чәчен бөдрәләткән, кашын-күзен *буяган*, иреннәре кып-кызыл яналар. (Г. Ибраһимов)
2. Берәр нәрсә сөртеп, ягып пычрату. Мәсәлән: Пычракка *буяу*. Кит көпчәк яныннан, күлмәгеңне *буягансың*. (И. Гази)

**Дару:** 1. Чирне яки авыртуны бетерү яисә киметү өчен кулланыла торган сыекча яки порошок хәлендәге матдә. Мәсәлән: Баш, йөрәк *даруы*. Күзгә *дару* салу.
2. Чирне яки авыруны, төрле зарарлы бөҗәкләрне һ.б.ш.ларны бетерү өчен кулланыла торган сыекча яки порошок хәлендәге матдә (агу). Мәсәлән: Таракан *даруы*. *Дару* сибү.

**Ис:** 1. Җисемнәрнең, әйберләрнең борын белән сизелә торган үзлеге. Мәсәлән: Һавадан кара туфрак *исе*, яңа киселгән нарат агачы *исе* аңкый. (И. Гази) Бу чәчәкләрдән шундый хуш *исләр* тарала. (Сөйләмнән)
2. Сасы ис. Мәсәлән: Нинди *ис*? Һәрбер кеше борынын кысып тоткан бүген? (Г. Тукай) – Әйдә, Ваня, үз бүлмәбездә *ис* бетте. (Т. Гыйззәт)

**Исле:** 1. Нинди дә булса хуш ис аңкытып торган. Мәсәлән:
*Исле* чәчәк өзелсә дә,
Исе кала болында. (Җыр)
Ул төенчеген чишеп, хуш *исле* кипкән мәтрүшкә чыгарды. (И. Гази)
2. Нинди дә булса сасы, начар ис аңкытып торган. Мәсәлән: *Исле* бүлмә. Имән күмере *исле* булыр. (Мәкаль)

**Куыру:** 1. Эссе һаваның, эссенең тәнгә килеп бәрелүе, тәнне кыздыруы турында әйтелә. Мәсәлән: Мунча ... башны *куырып* алырлык итеп кызу ягылган. (М. Гали)
2. Салкын һаваның, суыкның тәнне чеметеп-чеметеп алуы турында әйтелә. Мәсәлән: Урамга чыгарлар иде дә шул, кыш бабай бик яман *куыра*. (А. Алиш)

**Наз** *и.* 1. Иркәлек, йомшак мөнәсәбәт; иркәләү. Мәсәлән: Зариф --- бу балага биргән мәхәббәтен һәм *назын* үз Фәридәсенә биргән кебек тоядыр. *Ә. Еники* Әтисенең *назы* [Габдулланың] кайгысын сүндерми, дөрләтә генә. *Ә. Фәйзи*
2. Каприз, көйсезлек; *күч.* мәшәкать, борчу. Мәсәлән: Бу – Әсманың коры бер кокетлыгы, коры бер назыдыр. Ф. Әмирхан Кызы барның назы бар. *Мәкаль* Бал кортының балы бар, балга кадәр назы бар. *Мәкаль*

**Соңгы:** 1. Иң ахырга туры килгән, ахыргы, азакқы. Мәсәлән: *Соңгы* звонок. Поезд кузгалды. (М. Максуд)
2. Әле генә дөньяга чыккан, иң яңа. Мәсәлән: *Соңгы* мода белән киенү. Фәннең *соңгы* казанышлары.

**Тану**: 1. Асрым билгеләре буенча кешенең кем булуын яки предметның кемнеке яисә нинди төрдән булуын белеп алу. Мәсәлән:
– Юк, Разия, таныдым, бик *таныдым*, буегызны, шәүләгезне күргәч тә таныдым (Ф. Әмирхан)
2. Булганны инкяр итү, белмәгәнгә салыну, күрмәгән булып кылану. Мәсәлән: Күзгә карап *тану*. Бурычын *танган* – бөлгән, чирен *танган* – үлгән. (Мәкаль) Ифрат үз гаебен *танмады*. (А. Расих)

**Таралу** (дан): 1. Кешедән кешегә күчеп, бик күпләргә яхшы яктан мәгълүм булу; мактаулы булу. Мәсәлән: Бөтен илгә *таралды* челюскинчыларның даны. (Сөйләмнән)
2. Кешедән кешегә күчеп, бик күпләргә кире, начар яктан мәгълүм булу; яман атлы булу. Мәсәлән: Ил өстендә *таралган* бу гайбәт Таһир эше икән. (Ә. Айдар)

**Тону**: 1. Болганган кисәкчәләр төпкә утырып, үтә күренмәле хәлгә килү (су һ.б. сыеклыклар турында). Мәсәлән: Су болганыр да *тонар*, ил болганыр да тынар. (Мәкаль) Тыпырдап кысла үлгәч, күл дә *тонды*. (М. Гафури)
2. Пычранган, буланган һава яки су аша күренгән шикелле булу, ачыклыгын югалту. Мәсәлән: Сүнде йолдыз, калды төссез ай *тонып*. (Н. Исәнбәт) Күк йөзе караңгылана төште, урман салкынчаланды, йолдызлар бер яктырып, бер *тонып*, еракган-еракган җем-җем иттеләр, елтырадылар. (Ф. Әмирхан)

**Тонык**: 1. Тонган, саф, үтә күренмәле (су һәм башка сыеклыклар турында). Мәсәлән: *Тонык* күл. Чишмә *тонык* һ.б.
2. Ачыклыгын югалткан, болганган, төссез (су һәм башка сыеклыклар, предметлар турында). Мәсәлән: Күзләре *тонык*. Ай янгыр алдыннан *тонык*, аязыр алдыннан ачык күренә. (Сынамыш)

**Түбә**: 1. Берәр биек нәрсәнең иң югары өлеше, югары очы. Мәсәлән: Өй *түбәсе*. Яшькелт таулар зәңгәр күккә башларын сузып торалар. Нинди биекләр алар: итәкләрендә торып, *түбәләренә* карасаң, башыңнан түбәтәең төшеп китәр. (Д. Аппакова).
2. Иң түбән урын, иң түбән нокта. Мәсәлән: Мин бер тәгәрәп, бер торып, чокырның *түбәсенә* хәтле төштем. (Ш. Камал)

**Төссез**: 1. Төсе булмаган, үтә күренмәле. Мәсәлән: *Төссез* сыекча. *Төссез* газ.
2. Табигый төсен югалткан, тонык. Мәсәлән: *Төссез* тукыма. Бу искергән алачыгым һәм караңгы, һәм *төссез*. (Дәрдмәнд)
Янып торган теге җанлы күзләр
*Төссезләнеп* аска баттылар. (М. Гафури)

**Уба**: 1. Җиргә казылып ясалган чокыр; убылган урын. Мәсәлән: *Сентябрь*. Күктән тамчылар, агачлардан яфраклар коям, әрләннәрне, йомраннарны *убаларына* кадәр куам! (Г. Галиев)
2. Тигез җирдәге кечерәк калку урын. Мәсәлән:
Еракта ла җирдән, һай, күренә
*Убаларга* салган ташкала. (Җыр)

**Ур:** 1. Текә ярлы коры елга, тирән чокыр. Мәсәлән:
Кара урманның уртасында
Төлке уйный торган *урлар* бар. (Җыр)
2. Дошманнан саклану өчен, шәһәр һәм крепость тирәли койма урынына казылып ясалган вал (өелгән калкулык).

**Челәю:** 1. Акаю, зур итеп ачылу (күзләр турында). Күзеңне *челәйтмә*.
2. Кысылу; чепиләнү. Мәсәлән:
Чыпта суккан яшь кызларның
Ике күзе *челәйгән*. (Җыр)

**Чиллә:** 1. Җәй көне 25 нче июньнән 5 нче августка кадәр дәвам итә торган бик эссе вакыт (кайбер очракларда "җәйге" сүзе белән бергә килә). Мәсәлән: *Зөлхәмидә.* Үгезләр кигәвеннән бик куркалар бит. *Чилләдә* койрыкларын күтәреп чабалар. (Т. Гыйззәт)
2. Кыш көне 25 нче декабрьдән 5 нче февральгә кадәр дәвам итә торган бик салкын вакыт (кайбер очракларда "кышкы" сүзе белән бергә килә). Мәсәлән: Шибайдан яучы килеп, мәһәр акчасын алгач та, карт, башкалар кебек, кияүне кышкы *чилләдә* салкын келәткә ябарга ошатмады. (Г. Ибраһимов)

**Чүпләү:** 1. Чүп белән тутыру, чүп белән каплау, чисталыкны бозу. Мәсәлән: Көн жый, төн жый, бер яктан жыя барасың, икенче яктан *чүпли* баралар. (Г. Камал)
2.Таралып яткан кәгазь һәм башка вак нәрсәләрне – чүпне җыеп алу, чиста итү. Мәсәлән: Сабый, валчыкларны *чүпләп* бетергәч, әнисенең киезләнеп беткән чәчләре белән уйнагандай итенде. (Г. Гобәй)

**Шәфәкъ:** 1. Кояш баегеннан соң көнбатышта офыкта кояш нурларыннан була торган кызыллык. Мәсәлән: Илемнең бер читендә *шәфәкъ* сузылганда, таң сызыла башка читендә. (Ә. Исхак)
Йөзлекәй карчык баеп баручы кояшка, Зәй буеның яшел әрәмәләрен алсу төскә манган *шәфәкъ* нурына озак кына карап утырды. (Г. Ахунов)
2. Таң алдыннан була торган көнчыгыш офыктагы кызыллык. Мәсәлән: Иргәнге *шәфәкъ*. Дөрес, Габдулла ул кызны ут йотып сөйми әле, ләкин аңа булган мөнәсәбәте кояшның бик зур булып чыгар алдыннан күк читендә нәзек кенә *шәфәкъ* уты булып, кабыныр-кабынмас торуына охшый иде. (Ә. Фәйзи)

**Эх!:** 1. Соклану, таңга калу, гаҗәпләнүне белдерә. Мәсәлән:
*Эх*, күңелле, куакларда
Сайрап җибәрә былбыл.
*Эх*, шул былбылның тавышы
Бигрәк тә матур быел. (Ә. Ерикәй)
2. Гарьләнү, үкенү, шелтәләү һ.б.ш. тойгыларны белдерә. Мәсәлән: *Эх*, Нәфисә, ни генә әйтим соң сиңа? Нигә болай соң син, ә? (Г. Бәширов) *Эх*, бу тормыш... Көтмәгәндә, уйламаганда, авырып киттем. (Г. Әпсәләмов)

**Яну:** 1. Электр чылбырын тоташтырып, лампочканы яндырып җибәрү; яктылык чәчү. Мәсәлән: Мондый шатлыклы минутларда Шакир, бар җирдә дә ут *януын* теләп, стенадагы включательне борды. (Г. Минский)
2. Электр чылбырының өзелүе нәтиҗәсендә лампочканың сүнүе. Мәсәлән: Лампочка *янып* китте, алыштыра күр инде, балам. (Сөйләмнән)

## СҮЗЛЕККӘ ӨСТӘМӘ

### А

абайламыйча (рәв.) – юри (рәв.)
азак (рәв.) – башта (рәв.)
азаккы (сыйф.) – баштагы (сыйф.)
азактан (рәв.) – баштан (рәв.)
аерылышу (ф.) – кавышу (ф.)
аклама (ис.) – каралама (ис.)
аклау (ф.) – каралау (ф.)
аклау (ф.) – каралту (ф.)
аклык (ис.) – каралык (ис.)
актив (сыйф.) – пассив (сыйф.)
активлашу (ф.) – пассивлашу (ф.)
акрынаю (ф.) – шәбәю (ф.)
акчалата (рәв.) – бушлай (рәв.)
акыллы (сыйф.) – тиле (сыйф.)
алама (сыйф.) – начар (сыйф.)
алдагы (сыйф.) – арттагы (сыйф.)
алу I (ф.) – кушу (ф.)
алу II (ф.) – кайтару (ф.)
анда (рәв.) – биредә (рәв.)
аннан (рәв.) – моннан (рәв.)
англофил (ис.) – англофоб (ис.)
антипатия (ис.) – симпатия (ис.)
апогей (ис.) – перегей (ис.)
артында (рәв.) – алдында (рәв.)
архаизм (ис.) – неологизм (ис.)
атеист (ис.) – диндар (ис.)
ачлык (ис.) – туклык (ис.)
ачыгу (ф.) – тую (ф.)
ашыгу (ф.) – кабаланмау (ф.)
ашыгу (ф.) – сабыр итү (ф.)
аяусыз (сыйф.) – мәрхәмәтле (сыйф.)
аяусыз (сыйф.) – шәфкатьле (сыйф.)
аяусызлык (ис.) – мәрхәмәтлелек (ис.)
аяусызлык (ис.) – шәфкатьлелек (ис.)

### Ә

әдәпле (сыйф.) – дорфа (сыйф.)
әдәпле (сыйф.) – тупас (сыйф.)
әдәплелек (ис.) – әдәпсезлек (ис.)
әдәплелек (ис.) – дорфалык (ис.)
әдәпләнү (ф.) – әдәпсезләнү (ф.)
әйләнеч (сыйф.) – туры (сыйф.)
әкренлек (ис.) – тизлек (ис.)
әкренәйтү (ф.) – тизләтү (ф.)
әкренәйтү (ф.) – көчәйтү (ф.)
әлеге (рәв.) – баягы (рәв.)
әрәмгә (рәв.) – файдага (рәв.)
әхлаклы (сыйф.) – әхлаксыз (сыйф.)
әсирлек (ис.) – азатлык (ис.)
әсирлек (ис.) – хөррият (ис.)
әчелек (ис.) – төчелек (ис.)
әшәке (сыйф.) – яхшы (сыйф.)
әшәке (сыйф) – әйбәт (сыйф.)

### Б

байлык (ис.) – юклык (ис.)
баштан (рәв.) – ахырдан (рәв.)
башлам (ис.) – бетем (ис.)
башлаучы (ис.) – тәмамлаучы (ис.)
бәйрәм (ис.) – матәм (ис.)
бәйләү (ф.) – сүтү (ф.)
бәйләү (ф.) – чишү (ф.)
бәйләнешле (сыйф.) – бәйләнешсез (сыйф.)
бәләкәйләнү (ф.) – зураю (ф.)
бәяле (сыйф.) – бәясез (сыйф.)
белдерү (ф.) – яшерү (ф.)
берләшү (ф.) – таркалу (ф.)
бертоташтан (рәв.) – өзек-өзек (рәв.)
бертөсле (сыйф.) – төрле-төрле (сыйф.)
берьеллык (сыйф.) – күпьеллык (сыйф.)
ялгызы (рәв.) – күмәк (рәв.)
бизәү (ф.) – бозу (ф.)
бир (ф.) – мә (ф.)
бире (рәв.) – ары (рәв.)
биредә (рәв.) – тегендә (рәв.)
бозу (ф.) – төзәтү (ф.)
бозык (сыйф.) – әдәпле (сыйф.)
болытлы (сыйф.) – аяз (сыйф.)
болытлау (ф.) – аязаю (сыйф.)
бөгү (ф.) – турайту (ф.)
бөгелү (ф.) – тураю (ф.)
бөкре (сыйф.) – туры (сыйф.)
бөркү (сыйф.) – җиләс (сыйф.)
буаз (сыйф.) – кысыр (сыйф.)
булдыклы (сыйф.) – булдыксыз (сыйф.)
булышу (ф.) – комачаулау (ф.)

буш (сыйф.) – тыгыз (сыйф.)
буяу (ф.) – сөртү (ф.)
бушка (рәв.) – бәягә (рәв.) //
бушка (рәв.) – хакка (рәв.)
бушлата (рәв.) – акчага (рәв.)
бүлү (ф.) – тапкырлау (ф.)
былтыргы (рәв.) – быелгы (рәв.)

**В**

вагаю (ф.) – эреләнү (ф.)
ваемлы (сыйф.) – ваемсыз (сыйф.)
ваемлылык (ис.) – ваемсызлык (ис.)
вату (ф.) – төзәтү (ф.)
вату (ф.) – кору (ф.)
ватык (сыйф.) – төзек (сыйф.)

**Г**

гадиләнү (ф.) – катлаулану (ф.)
гадиләштерү (ф.) – катлауландыру (ф.)
гадәтле (сыйф.) – гадәтсез (сыйф.)
гамьле (сыйф.) – гамьсез (сыйф.)
гомуми (сыйф.) – хосусый (сыйф.)
гомуми (сыйф.) – шәхси (сыйф.)
гуманизм (ис.) – мезантропизм (ис.)

**Д**

дәвамлы (сыйф.) – өзек-өзек (сыйф.)
диахрония (ис.) – синхрония (ис.)
динчел (сыйф.) – динсез (сыйф.)
дөреслек (ис.) – ялганлык (ис.)
дуамал (ис.) – акыллы (ис.)

**Е**

егу (ф.) – торгызу (ф.)
елгыр (сыйф.) – сүлпән (сыйф.)
елгырлык (ис.) – сүлпәнлек (ис.)
елдам (сыйф.) – сүлпән (сыйф.)
ераклашу (ф.) – якынлашу (ф.)
ешайту (ф.) – сирәгәйтү (ф.)
ешаю (ф.) – сирәгәю (ф.)
ешлау (ф.) – сирәгәйтү (ф.)

**Ж**

җаваплы (сыйф.) – җавапсыз (сыйф.)
җайлы (сыйф.) – җайсыз (сыйф.)
җайлы (сыйф.) – уңайсыз (сыйф.)
җайлылык (ис.) – уңайсызлык (ис.)
җәенке (сыйф.) – кысынкы (сыйф.)
җәелү (ф.) – кысылу (ф.)
җәһәт (рәв.) – ашыкмыйча (рәв.)
җәһәт (рәв.) – салмак (рәв.)
җебегән (сыйф.ф.) – булдыклы (сыйф.)
җигү (ф.) – тугару (ф.)
җимерек (сыйф.) – төзек (сыйф.)
җитез (сыйф.) – үшән (сыйф.)
җыелу (ф.) – таркалу (ф.)
җыерылу (ф.) – язылу (ф.)
җылыну (ф.) – суыну (ф.)
җылыту (ф.) – суыту (ф.)

**З**

зарарсыз (сыйф.) – зарарлы (сыйф.)
зиһенле (сыйф.) – зиһенсез (сыйф.)
зурлау (ф.) – хурлау (ф.)

**И**

игелекле (сыйф.) – игелексез (сыйф.)
игътибарлы (сыйф.) – битараф (сыйф.)
идән (ис.) – түшәм (ис.)
икеле (сыйф.) – анык (сыйф.)
икеләнүле (сыйф.) – икеләнүсез (сыйф.)
икеләнүчән (сыйф.) – тәвәккәл (сыйф.)
икърар (ис.) – инкяр (ис.)
илтифатлы (сыйф.) – илтифатсыз (сыйф.)
иманлы (сыйф.) – имансыз (сыйф.)
импорт (ис.) – экспорт (ис.)
инсафлы (сыйф.) – инсафсыз (сыйф.)
инану (ф.) – икеләнү (ф.)
индивидуаль (сыйф.) – коллектив (сыйф.)
интегү (ф.) – рәхәтләнү (ф.)
искечә (рәв.) – яңача (рәв.)
исле (сыйф.) – иссез (сыйф.)
исәпле (сыйф.) – исәпсез (сыйф.)
ихтирамлылык (ис.) –
ихтирамсызлык (ис.)
изләшү (ф.) – читләшү (ф.)

инкү (сыйф.) – калку (сыйф.)
инкүлек (ис.) – калкулык (ис.)
инү (ф.) – ашу (ф.)

## Й

йомшару (ф.) – катыру (ф.)
йомшару (ф.) – кату (ф.)
йончу (ф.) – хәлләнү (ф.)
йөзтүбән (рәв.) – чалкан (рәв.)

## К

кабу (ф.) – ычкыну (ф.)
каеру (ф.) – беркетү (ф.)
кайнату (ф.) – суыту (ф.)
кайчак (рәв.) – һәрвакыт (рәв.)
калку (сыйф.) – инкү (сыйф.)
калынайту (ф.) – юкарту (ф.)
калынаю (ф.) – юкару (ф.)
каптыру (ф.) – ычкындыру (ф.)
каралама (ис.) – аклама (ис.)
каралҗым (сыйф.) – аксыл (сыйф.)
каршы (сыйф.) – яклы (сыйф.)
катлаулы (сыйф.) – гади (сыйф.)
каушау (ф.) – кыюлану (ф.)
каудар (сыйф.) – басалкы (сыйф.)
качу (ф.) – тотылу (ф.)
качу (ф.) – эләгү (ф.)
кертү (ф.) – чыгару (ф.)
керенте (сыйф.) – чыгынты (сыйф.)
кечелек (ис.) – олылык (ис.)
кечкенә (сыйф.) – дәү (сыйф.)
кечерәйтү (ф.) – зурайту (ф.)
кечерәю (ф.) – зураю (ф.)
кибү (ф.) – юешләнү (ф.)
кибү (ф.) – сулану (ф.)
кидерү (ф.) – салдыру (ф.)
киерү (ф.) – җыеру (ф.)
килбәтле (сыйф.) – килбәтсез (сыйф.)
кимү (ф.) – ишәю (ф.)
кимү (ф.) – үсәлү (ф.)
киң (сыйф.) – кысан (сыйф.)
кичәге (рәв.) – бүгенге (сыйф.)
коралландыру (ф.) –
коралсызландыру (ф.)
кору (ф.) – юешләнү (ф.)
кору (ф.) – дымлану (ф.)
корылу (ф.) – сүтелү (ф.)
корыту (ф.) – юешләү (ф.)
космополит (сыйф.) – милләтпәрвар (сыйф.)
космополит (сыйф.) – патриот (сыйф.)
космополитизм (ис.) – патриотизм (ис.)
котлы (сыйф.) – котсыз (сыйф.)
кою (ф.) – яру (ф.)
кою (ф.) – түгү (ф.)
көйле (сыйф.) – көйсез (сыйф.)
көндезге (сыйф.) – төнге (сыйф.)
көпшәк (сыйф.) – тыгыз (сыйф.)
көпшәкләнү (ф.) – тыгызлану (ф.)
көрәю (ф.) – арыклану (ф.)
көю (ф.) – сөенү (ф.)
көю (ф.) – шатлану (ф)
кояз (сыйф.) – шапшак (сыйф.)
куалау (ф.) – чакыру (ф.)
куу (ф.) – чакыру (ф)
кубару (ф.) – ябыштыру (ф)
кубу (ф.) – ябышу (ф.)
куну (ф.) – очып китү (ф.)
кулай (сыйф.) – уңайсыз (сыйф.)
кулай (сыйф.) – җайсыз (сыйф.)
купай (сыйф.) – басалкы (сыйф.)
купшы (сыйф.) – шапшак (сыйф.)
кушу (ис.) – алу (ис.)
куркыныч (сыйф.) – хәвефсез (сыйф.)
кую (ф.) – алу (ф.)
күбәйтү (ф.) – азайту (ф.)
күмү (ф.) – казу (ф.)
күндәм (сыйф.) – тынгысыз (сыйф.)
күндәм (сыйф.) – чорсыз (сыйф.)
күперенке (сыйф.) – батынкы (мыйф.)
күплек (ис) – берлек (ис.)
күпләп (рәв.) – азлап (рәв.)
күптән (рәв.) – әле генә (рәв)
күптән (рәв.) – яңа гына (рәв.)
күптәнге (рәв.) – яңа (рәв.)
күренекле (сыйф.) – күренексез (сыйф.)
күркәм (сыйф.) – ямьсез (сыйф.)
күркәмләнү (ф.) – ямьсезләнү (ф.)
күрәләтә (рәв.) – белмичә (рәв.)
күчмә (сыйф.) – утрак (сыйф.)
кыенлашу (ф.) – җиңелләшү (ф.)
кыенлык (ис.) – җиңеллек (ис.)
кыенсыну (ф.) – батыраю (ф)

кыздыру (ф.) – сүрелдерү (ф.)
кызу I (сыйф.) – салмак (сыйф.)
кызу II (ф.) – сүрелү (ф.)
кызыктыру (ф.) – биздерү (ф.)
кырлач (сыйф.) – челлә (сыйф.)
кырый (сыйф.) – чит (сыйф.)
кысык (сыйф.) – иркен (сыйф.)
кысынкы (сыйф.) – иркен (сыйф.)
кысынкылык (ис.) – иркенлек (ис.)
кыю (сыйф.) – тыйнак (сыйф.)

Л

ләззәтләнү (ф.) – кайгыру (ф.)
ләззәтсез (сыйф.) – ләззәтле (сыйф.)
лычма (сыйф.) – коры (сыйф.)
литота (ис.) – гипербола (ис.)

М

мавыктыру (ф.) – биздерү (ф.)
майна (ымл.) – вира (ымл.)
максималь (сыйф.) – минималь (сыйф.)
максимум (ис.) – минимум (ис.)
материализм (ис.) – идеализм (ис.)
матурлану (ф.) – ямьсезләнү (ф.)
матурлау (ф.) – ямьсезләү (ф.)
мәгънәле (сыйф.) – мәгънәсез (сыйф.)
мәгълүм (сыйф.) – билгесез (сыйф.)
мәдхия (ис.) – мәрсия (ис.)
мәҗбүри (сыйф.) – ирекле (сыйф.)
мәрхәмәтле (сыйф.) – мәрхәмәтсез (сыйф.)
мәрхәмәтлелек (ис.) –
мәрхәмәтсезлек (ис.)
минималь (сыйф.) – максималь (сыйф.)
минимум (ис.) – максимум (ис.)
миһербанлы (сыйф.) –
миһербансыз (сыйф.)
миһербанлылык (ис.) –
миһербансызлык (ис.)
мондагы (алм.) – андагы (алм.)
мондагы (сыйф.) – тегендәге (сыйф.)
моннан (рәв.) – тегеннән (рәв.)
моңсулык (ис.) – күңелчәлек (ис.)
мөмкин (хәб.сүз) – юк (хәб.сүз)
мөстәкыйль (сыйф.) – бәйле (сыйф.)
муллык (ис.) – житешмәүчәнлек (ис.)
муллык (ис.) – мохтаҗлык (ис.)
мутлык (ис.) – җитдилек (ис.)

Н

назлау (ф.) – битәрләү (ф.)
намуслы (сыйф.) – намуссыз (сыйф.)
намуслылык (ис.) – намуссызлык (ис.)
натураль (сыйф.) – ясалма (сыйф.)
начарлану (ф.) – әйбәтләнү (ф.)
начарлану (ф.) – яхшылану (ф.)
начарлык (ис.) – яхшылык (ис.)
нәни (сыйф.) – дәү (сыйф.)
наян (сыйф.) – җитди (сыйф.)
наянлык (ис.) – җитдилек (ис.)
нәзакәтле (сыйф.) – дорфа (сыйф.)
нәзакәтле (сыйф.) – тупас (сыйф.)
нәзек (сыйф.) – юан (сыйф.)
нечкә (сыйф.) – юан (сыйф.)
ныгыту (ф.) – бушату (ф.)
нык (сыйф.) – буш (сыйф.)
нык (сыйф.) – йомшак (сыйф.)

О

оештыру (ф.) – таркату (ф.)
оештырылу (ф.) – таркатылу (ф.)
оешу (ф.) – таркалу (ф.)
озайту (ф.) – кыскарту (ф.)
озынлык (ис.) – кыскалык (ис.)
оныту (ф.) – хәтерләү (ф.)
охшашлык (ис.) – аерма (ис.)
оч (ис.) – төп (ис.)
очраклы (сыйф.) – махсус (сыйф.)

Ө

өерелү (ф.) – таркалу (ф.)
өерү (ф.) – тузгыту (ф.)
өзек (сыйф.) – тоташ (сыйф.)
өзлексез (сыйф.) – өзек-өзек (сыйф.)
өйләнгән (сыйф.ф.) – буйдак (сыйф.)
өйләнү (ф.) – аерылу (ф.)
өлгерү (ф.) – соңлау (ф.)
өмет (ис.) – өметсезлек (ис.)
өметләнү (ф.) – өметсезләнү (ф.)
өркү (ф.) – кыюлану (ф.)

өс (ис.) – ас (ис.)
өстәлү (ф.) – киму (ф.).
өстәү (ф.) – киметү (ф)
өстән (рәв.) – түбәннән (рәв.)
өстенлек (ис.) – кимлек (ис)

П

пакъ (сыйф.) – пычрак (сыйф.)
пакълау (ф.) – пычрату (ф.)
пакълек (ис.) – пычраклык (ис.)
палаталь (сыйф.) – веляр (сыйф.)
патриций (ис.) – плебей (ис.)
пешкән (сыйф.ф.) – чи (сыйф.)
плюс (ис.) – минус (ис.)
позитив (сыйф.) – негатив (сыйф.)
пошмас (сыйф.) – пошынулы (сыйф.)
прогресс (ис.) – регресс (ис.)
прогрессив (сыйф.) – реакцион (сыйф.)
прогрессив (сыйф.) – регрессив (сыйф.)
пөхтәлек (ис.) – шапшаклык (ис.)
пычраклык (ис.) – чисталык (ис.)
пычрану (ф.) – чистарыну (ф.)
пычрату (ф.) – чистарту (ф.)

Р

радиоалгыч (ис.) – радиотапшыргыч (ис.)
раслау (ф.) – инкарьлау (ф.)
рациональ (сыйф.) –
иррациональ (сыйф.)
рәтләү (ф.) – бозу (ф.)
рәхимле (сыйф.) – рәхимсез (сыйф.)
рәхимлелек (ис) – рәхимсезлек (ис.)
революция (ис.) – контрреволюция (ис.)
регресс (ис.) – прогресс (ис.)
ризалык (ис.) – ризасызлык (ис.)
риялы (сыйф.) – риясыз (сыйф.)
рухлы (сыйф.) – рухсыз (сыйф.)
рухлану (ф.) – рухсызлану (ф.)

С

сабыр (сыйф.) – түземсез (сыйф.)
саваплы (сыйф.) – гөнаһлы (сыйф.)
савыгу (ф.) – авыру (ф.)
саклау (ф.) – урлату (ф.)
салдыру (ф.) – кидерү (ф.)
салмак (рәв.) – кызу (рәв.)
салмак (рәв.) – тиз (рәв.)
самими (сыйф.) – риялы (сыйф.)
саф (сыйф.) – болганчык (сыйф.)
саф (сыйф.) – тынчу (сыйф.)
саф (сыйф.) – бозык (сыйф.)
саңгырау (сыйф.) – яңгырау (сыйф.)
сибү (ф.) – жыю (ф.)
симез (сыйф.) – ябык (сыйф.)
симезлек (ис.) – ябыклык (ис.)
симертү (ф.) – ябыктыру (ф.)
симерү (ф.) – ябыгу (ф.)
симметрия (ис.) – асимметрия (ис.)
синхрония (ис.) – диахрония (ис.)
сирәк (рәв.) – еш (рәв.)
сирәкләү (ф.) – ешайту (ф.)
сөйкемле (сыйф.) – сөйкемсез (сыйф.)
сөйкемлеләнү (ф.) – сөйкемсезләнү (ф.)
сөтләч (сыйф.) – сөтсез (сыйф.)
сөтчел (сыйф.) – сөтсез (сыйф.)
сулау I (ф.) – өрү (ф.)
сулау II (ф.) – киптерү (ф.)
суыну (ф.) – жылыну (ф.)
сүзсез (сыйф.) – сүзчән (сыйф.)
сүлпән (сыйф.) – житез (сыйф.)
сүлпәнлек (ис.) – житезлек (ис.)
сүрән (сыйф.) – кызу (сыйф.)
сүрелү (ф.) – эсселәнү (ф.)
сүрелү (ф.) – кызу (ф.)
сыек (сыйф.) – каты (сыйф.)
сыек (сыйф.) – куе (сыйф.)
сырхау (сыйф.) – таза (сыйф.)

Т

табигый (сыйф.) – ясалма (сыйф.)
тагу (ф.) – ычкындыру (ф.)
тазарту (ф.) – пычрату (ф.)
талгын (рәв.) – шәп (рәв.)
таркалу (ф.) – оешу (ф.)
таркату (ф.) – оештыру (ф.)
таркау (сыйф.) – жыйнак (сыйф.)
таркаулык (ис.) – жыйнаклык (ис.)
тарту (ф.) – этү (ф.)
тартыну (ф.) – әрсезләнү (ф.)
тартынучан (сыйф.) – әрсез (сыйф.)

тарыгу (ф.) – киңәю (ф.)
татулашу (ф.) – низаглашу (ф.)
тәмле (сыйф.) – тәмсез (сыйф.)
тәрбияле (сыйф.) – тәрбиясез (сыйф.)
текә (сыйф.) – сөзәк (сыйф.)
тигез (сыйф.) – сикәлтәле (сыйф.)
тирән (сыйф.) – сай (сыйф.)
тискәре (сыйф.) – уңай (сыйф.)
тоба (сыйф.) – сай (сыйф.)
торгынлык (ис.) – алгарыш (ис.)
тотрыклы (сыйф.) – тотрыксыз (сыйф.)
тою (ф.) – сизмәү (ф.)
трагедия (ис.) – комедия (ис.)
туару (ф.) – жигү (ф.)
төз (сыйф.) – кәкре (сыйф.)
төзәтү (ф.) – бозу (ф.)
төзек (сыйф.) – ватык (сыйф.)
төзеклек (ис.) – җимереклек (ис.)
төксе (сыйф.) – мөлаем (сыйф.)
төнге (сыйф.) – көндезге (сыйф.)
төнлә (рәв.) – көндез (рәв.)
төньяк (ис.) – көньяк (ис.)
төпләнү (ф.) – күченү (ф.)
төрле (сыйф.) – бертөрле (сыйф.)
төшенке (сыйф.) – күтәренке (сыйф.)
тудыру (ф.) – үтерү (ф.)
тузгыту (ф.) – җыю (ф.)
туздыру (ф.) – җыю (ф.)
тулаем (рәв.) – өлешчә (рәв.)
туплану (ф.) – таралу (ф.)
тупый(к) (сыйф.) – очлы (сыйф.)
турайту (ф.) – кәкрәйтү (ф.)
тураю (ф.) – кәкреләнү (ф.)
туры (сыйф.) – күчерелмә (сыйф.)
турыдан (рәв.) – әйләнгечтән (рәв.)
турыдан (рәв.) – кинаялап (рәв.)
турыдан (рәв.) – читләтеп (рәв.)
турылык (ис.) – кәкрелек (ис.)
тутыру (ф.) – бушату (ф.)
тую (ф.) – ачыгу (ф.)
түгү (ф.) – тутыру (ф.)
түземле (сыйф.)– түземсез (сыйф.)
түләүле (рәв.) – бушлай (рәв.)
тыгыз (сыйф.) – буш (сыйф.)
тыгыз (сыйф.) – сирәк (сыйф.)
тыгызлану (ф.) – сирәкләнү (ф.)
тыелу (ф.) – ярсу (ф.)
тыл (ис.) – фронт (ис.)
тымызык (сыйф.) – зилзиләле (сыйф.)
тынлык (ис.) – шау-шу (ис.)
тыныч (сыйф.) – ярсу (сыйф.)
тынычлану (ф.) – борчылу (ф.)
тыпру! (ымл.) – на! (ымл.)
тырышу (ф.) – ялкаулану (ф.)
тышлык (ис.) – эчлек (ис.)
тыю (ф.) – рөхсәт итү (ф.)
тыңлаусыз (сыйф.) – тыңлаучан (сыйф.)

## У

уенчак (сыйф.) – җитди (сыйф)
уенчыл (сыйф.) – кырыс (сыйф.)
уйдырма (ис.) – чынлык (ис.)
уйламыйча (рәв.) – уйлап (рәв.)
уйсулык (ис.) – калкулык (ис.)
уң (сыйф.) – тискәре (сыйф.)
уңайлы (сыйф.) – җайсыз (сыйф.)
уңганлык (ис.) – ялкаулык (ис.)
уңышлы (сыйф.) – уңышсыз (сыйф.)
урау (ф.) – сүтү (ф.)
утыру (ф.) – басу (ф.)
уяну (ф.) йоклау (ф.)

## Ү

үзләшү (ф.) – читләшү (ф.)
үзләшү (ф.) – ятсыну (ф.)
үр (ис.) – үзән (ис.)
үрсәләнү (ф.) – хафаланмау (ф.)
үткен (сыйф.) – үтмәс (сыйф.)
үткер (сыйф.) – үтмәс (сыйф.)
үчле (сыйф.) – үчсез (сыйф.)

## Ф

фашист (ис.) – антифашист (ис.)
филантропия (ис.) – мезантропия (ис.)
финиш (ис.) – старт (ис.)

## Х

хафалану (ф.) – кинәнү (ф.)
хәйләкәр (сыйф.) – беркатлы (сыйф.)
хезмәт (ис.) – ял (ис.)
хисле (сыйф.) – хиссез (сыйф.)

холыклы (сыйф.) – холыксыз (сыйф.)
хосусый (сыйф.) – гомуми (сыйф.)
хөрмәтләү (ф.) – хурлау (ф.)
хөррият (ис.) – тоткынлык (ис.)
хыялый (сыйф.) – реаль (сыйф.)

**һ**

һавалы (сыйф.) – һиммәтле (сыйф.)
һичтуктаусыз (рәв.) – өзек-өзек (рәв.)
һәрьяклы (сыйф.) – берьяклы (сыйф.)
һәйбәт (сыйф.) – яман (сыйф.)

**Ч**

чалкан (рәв.) – йөзтүбән (рәв.)
чибәрлек (ис.) – ямьсезлек (ис.)
чистарту (ф.) – пычрату (ф.)
читен (сыйф.) – ансат (сыйф.)
чишелү (ф.) – төйнәлү (ф.)
чишендерү (ф.) – киендерү (ф.)
чишенү (ф.) – киенү (ф.)
чоку (ф.) – күмү (ф.)
чукрак (сыйф.) – сак (сыйф.)
чүпләү (ф.) – чәчү (ф.)
чүпле (сыйф.) – чиста (сыйф.)
чыгым (ис.) – керем (ис.)
чыдамлы (сыйф.) – түземсез (сыйф.)
чылату (ф.) – киптерү (ф.)

**Ш**

шакшы (сыйф.) – чиста (сыйф.)
шәбәю (ф.) – акрынаю (ф.)
шәп (рәв.) – салмак (рәв.)
шәрә (сыйф.) – киемле (сыйф.)
шәфкатьле (сыйф.) – шәфкатьсез (сыйф.)
шәфкатьлелек (ис.) – шәфкатьсезлек (ис.)
шәфәкъ (ис.) – тан (ис.)
шик (ис. ) – ышаныч (ис.)
шикле (сыйф.) – шиксез (сыйф.)
шома (сыйф.) – кытыршы (сыйф.)
шук (сыйф.) – житди (сыйф.)
шыксыз (сыйф.) – матур (сыйф.)
шыксызлык (ис.) – матурлык (ис.)
шым (сыйф.) – шаулы (сыйф.)
шыпырт (рәв.) – кычкырып (рәв.)

**Ы**

ыгы-зыгы (ис.) – тынлык (ис.)
ызгыш (ис.) – татулык (ис.)
ыспай (сыйф.) – шапшак (сыйф.)
ычкыну (ф.) – эләгү (ф.)
ышандыру (ф.) – алдау (ф.)

**Э**

эволюция (ис.) – революция (ис.)
эволюцион (сыйф.) –
революцион (сыйф.)
эгоист (ис.) – альтруист (ис.)
экскурсия (ис.) – рекурсия (ис.)
эләгү (ф.) – ычкыну (ф.)
эләктерү (ф.) – ычкындыру (ф.)
элекке (сыйф.) – хәзерге (сыйф.)
элеккечә (рәв.) – хәзергечә (рәв.)
элементар (сыйф.) – катлаулы (сыйф.)
элү (ф.) – алу (ф.)
эпилог (ис.) – пролог (ис.)
эрү (ф.) – туңу (ф.)
эрү (ф.) – кату (ф.)
эчкәре (рәв.) – тышкары (рәв.)
эчкерле (сыйф.) – эчкерсез (сыйф.)
эчлек (ис.) – тышлык (ис.)
эчтә (рәв.) – тышта (рәв.)
эчтән (рәв.) – тыштан (рәв.)
эшкуар (ис.) – җилкуар (ис.)
эшлекле (сыйф.) – эшлексез (сыйф.)
эшлеклелек (ис.) – эшлексезлек (ис.)
эшсөяр (ис.) – ялкау (ис.)

**Ю**

юанаю (ф.) – нечкәрү (ф.)
юату (ф.) – кыерсыту (ф.)
юату (ф.) – үпкәләтү (ф.)
юашлану (ф.) – усаллану (ф.)
юашлык (ис.) – усаллык (ис.)
югартын (рәв.) – астан (рәв.)
юешләнү (ф.) – кибү (ф.)
юкару (ф.) – калынаю (ф.)
юри (рәв.) – чынлап (рәв.)

## я

ябу (ф.) – ачу (ф.)
ябыгу (ф.) – симерү (ф.)
ябыштыру (ф.) – кубару (ф.)
ягу (ф.) – сүндерү (ф.)
ягымлылык (ис.) – ягымсызлык (ис.)
язгы (сыйф.) – көзге (сыйф.)
язын (рәв.) – көзен (рәв.)
яклау (ф.) – җәберләү (ф.)
яклаучы (ис.) – җәберләүче (ис.)
якынайту (ф.) – ерагайту (ф.)
якынлык (ис.) – ераклык (ис.)
якынча (рәв.) – төгәл (рәв.)
ял (ис.) – эш (ис.)
яла (ис.) – дөреслек (ис.)
ялгану (ф.) – өзелү (ф.)
ялгау (ф.) – өзү (ф.)
ямансу (рәв.) – рәхәт (рәв.)
яраклы (сыйф.) – файдасыз (сыйф.)
яңарту (ф.) – искертү (ф.)
яңару (ф.) – искерү (ф.)
яңача (рәв.) – искечә (рәв.)
ярлылык (ис.) – байлык (ис.)
ярсу (сыйф.) – басалкы (сыйф.)
ярсу (ф.) – сабырлану (ф.)
ясалма (сыйф.) – табигый (сыйф.)
ясау (ф.) – вату (ф.)
ясау (ф.) – җимерү (ф.)
ятсыну (ф.) – үзсенү (ф.)
яхшылану (ф.) – начарлану (ф.)
яшәрү (ф.) – картаю (ф.)
яшертен (рәв.) – ачыктан-ачык (рәв.)
яшертен (рәв.) – турыга (рәв.)
яшерү (ф.) – табу (ф.)
яшерү (ф.) – фаш итү (ф.)